ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис, Верхнеуслонский район, Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
28.02.2018

г. Иннополис

КАРАР
№ 12

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеген шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 3.1 бүлеге нигезендә, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеген шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләргә, алар Иннополис шәһәре халкының җирле әһәмияттәге объектларына минималь дәрәҗәдә тәэмин ителешнең исәп-хисап күрсәткечләрен һәм Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре халкы өчен мондый объектларның территориаль яктан файдалана алуының мөмкин булган максималь дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләрен үз эченә ала.

2. Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәре башкарма комитетын Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеген шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары проектын әзерләү өчен җаваплы итеп билгеләргә.

3. Әлеге карар кабул ителгән вакыттан алып бер ай дәвамында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеген шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын эшләү срогын билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеген шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары проектын эшләүгә техник йөкләмәне Кушымта нигезендә расларга.

5. Иннополис шәһәре башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, төзелеш һәм архитектура бүлеге башлыгына Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеген

шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары проектын әзерләү буенча тәкъдимнәр җыюны һәм гомумиләштерүне тәэмин итәргә.

6. 7 көн эчендә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Интернет челтәрендә Югары Ослан муниципаль районының мәгълүмати сайтына (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru/) урнаштырырга .

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Р.Шагалеев

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 28 февраленнән 12нче номерлы Карарына Кушымта

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелеше проектының җирле нормативлары проектын эшләү» темасы буенча эшне башкаруга

ТЕХНИК БИРЕМ

| № т/б | Мәгълүматлар һәм таләпләр исемлеге | Мәгълүматларның һәм таләпләрнең эчтәлеге |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Фәнни-техник продукция төре | Муниципаль берәмлекне шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары |
| 2 | Башкаручы | Иннополис шәһәре Башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, төзелеш һәм архитектура бүлеге |
| 4 | Фәнни-тикшеренү эшен башкару өчен нигез | «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеген шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү турында» Иннополис шәһәре Башкарма комитеты карары |
| 5 | Тикшеренү объекты, аның төп характеристикалары | «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе |
| 6 | Эшнең максаты | Түбәндәге өлкәләргә караган «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге объектлары белән тәэмин ителешнең минималь мөмкин дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре җыелмасын билгеләү:<br>шәһәрне электр һәм газ белән тәэмин итү;<br>«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендә торак пунктлар чикләреннән тыш җирле әһәмияттәге автомобиль юллары, транспорт хезмәте күрсәтү;<br>мәгариф;<br>сәламәтлек саклау;<br>мәгълүматлаштыру һәм элемтә;<br>мәдәният һәм ял вакытын оештыру;<br>социаль тәэмин итү һәм социаль яклау; |

| № т/б | Мәгълүматлар һәм таләпләр исемлеге | Мәгълүматларның һәм таләпләрнең эчтәлеге |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | физик культура һәм массакүләм спорт;<br>көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерү һәм эшкәртү,<br>җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү;<br>«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә бәйле башка өлкәләр.<br>Иннополис шәһәре халкы өчен мондый объектларның территориаль файдалана алу мөмкинлегенең максималь мөмкин булган дәрәҗәдә исәп-хисап күрсәткечләрен билгеләү. |
| 7 | Эшләр башкаруның норматив-хокукый базасы | 1.Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы ФЗ 190, 29.12.2004 ел<br>2.«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон<br>3.«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы<br>4.СП 42.13330.2011 «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү»<br>5.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 27 декабрендәге 1071 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативлары<br>6.Башка норматив хокукый актлар һәм норматив техник документлар |
| 8 | Эшне башкару өчен беренчел мәгълүматлар<br>- | Эшләрне башкару өчен кирәкле башлангыч мәгълүмат исемлеге Башкаручы тарафыннан формалаштырыла, башлангыч мәгълүмат җыю Башкаручы тарафыннан башкарыла. |
| 9 | Тапшырыла торган материалларның составы һәм эчтәлеге | «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеген шәһәр төзелешен проектлау нормативлары проекты составы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.2 статьясындагы 5 өлеше нигезләмәләренә туры килергә һәм түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:<br>төп өлеш (шәһәрнең җирле әһәмияттәге объектлары белән тәэмин ителешнең минималь мөмкин булган дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре һәм мондый объектларның шәһәр халкы өчен максималь мөмкин булган территория уңайлылыгының исәп-хисап күрсәткечләре);<br>шәһәр төзелешен проектлау нормативларының |

| № т/б | Мәгълүматлар һәм таләпләр исемлеге | Мәгълүматларның һәм таләпләрнең эчтәлеге |
| --- | --- | --- |
| 1 | 2 | 3 |
| | | төп өлешендәге исәп-хисап күрсәткечләрен нигезләү материаллары;<br>шәһәр төзелешен проектлау нормативларының төп өлешендә булган исәп-хисап күрсәткечләрен куллану кагыйдәләре һәм өлкәсе.<br>«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеген шәһәр төзелешен проектлау нормативларын әзерләү түбәндәгеләрне исәпкә алып башкарылырга тиеш:<br>шәһәрнең административ-территориаль корылышын;<br>«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендә урнашкан территорияләрдә шәһәр халкының социаль-демографик составы һәм тыгызлыгы;<br>табигать-климат шартлары;<br>шәһәрнең социаль-икътисадый үсеш программалары;<br>шәһәрнең социаль-икътисадый үсеш фаразы;<br>«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендә урнашкан шәһәрнең җирле үзидарә органнары һәм кызыксынучы затлар тәкъдимнәрен. |
| 10 | Эш нәтиҗәләрен килештерү | Башкаручы кызыксынган затларның эш нәтиҗәләрен килештерү барышында алынган искәрмәләргә һәм тәкъдимнәргә җавап бирә, кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алуның нигезле нигезләмәләрен әзерли, эш нәтиҗәләренә төзәтмәләр кертә. |
| 11 | Тапшырыла торган материалларның формасы | Материалларны тапшырырга:<br>- кәгазь чыганакларда А4 форматында - 2 нөсхә .<br>Эш нәтиҗәләренең электрон версиясе DOC (DOCX, RTF) форматында мәгълүмат йөртүчеләрдә бирелә. |